**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**“Татар халык әкиятләре” темасын йомгаклау**

**1. Нәрсә ул әкият?**

а) халык иҗатының эпик жанрларыннан берсе, могҗизалы һәм маҗаралы вакыйгаларга, көнкүрешкә бәйләнешле хәлләргә корылган социаль эчтәлекле фантастик әсәр;

ә) кыска, образлы, шигъри формадагы, гыйбрәтле, тормыш итү тәҗрибәсенә нигезләнгән халык авыз иҗаты әсәре;

б) бала тирбәткәндә җырлана торган җыр.

**2. Әкиятләр ничә төркемгә бүленә?**

а) ике;

ә) биш;

б) өч.

**3. «Төлке белән Торна», «Аю белән Төлке», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләре нинди төргә карый?**

а) тылсымлы әкият;

ә) көнкүреш әкияте;

б) хайваннар турындагы әкият.

**4. «Ак байтал» әкияте ничек башлана?**

а) борын-борын заманда булган, ди, бер урта хәлле крестьян;

ә) борын заманда бер карчыкның өч кызы булган, ди;

б) берәүнең бер кызы белән бер улы булган, ди.

**5. «Ак байтал» әкиятенең төп герое кем?**

а) карт;

ә) Тиле;

б) олы малайлар.

**6. Агайның ничә малае була?**

а) берәү;

ә) икәү;

б) өчәү.

**7. Тиле гаиләдә ничәнче бала була?**

а) беренче;

ә) икенче;

б) өченче.

**8. Ак байталны карт күпмегә сата?**

а) бер мең алтынга;

ә) өч мең алтынга;

б) бер капчык алтынга.

**9.Үги кызны урманга кем илтә?**

а) әтисе;

ә) агасы;

б) үги әнисе.

**10.Карчык кызга нинди сандык бирә?**

а) яшел сандык;

ә) кызыл сандык;

б) кара сандык

**11. «Хәйләкәр төлке» әкияте нинди төр әкияткә керә?**

а) хайваннар турындагы;

ә) көнкүреш әкияте;

б) тылсымлы әкият.

**12. «Солдат балтасы» әкиятенең төрен билгеләгез.**

а) хайваннар турындагы;

ә) көнкүреш әкияте;

б) тылсымлы әкият.

## Ачкыч

1. А
2. Б
3. Б
4. А
5. Ә
6. Б
7. Б
8. Ә
9. Ә
10. А
11. А
12. Ә

# Бәяләү

# 11-12 балл – “5”ле

# 9-10 балл – “4”ле

# 6-8 балл – “3”ле